ЯКШӘМБЕ
21 ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 43 (6765)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Кызыл Армиянең 25 еллыгына карата ВКП (б) Үзәк Комитеты лозунглары

1. Яшәсен, Ватаныбызның намусы, азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен немец-фашист басып алучыларга каршы геройларча көрәшүче Кызыл Армия!

Кызыл Армиянең егерме биш еллыгын дошман өстеннән яңа җиңүләр белән истә калдырыйк!

2. Яшәсен Бөек Совет халкы, аның немец-фашист басып алучыларны җиңү өчен ныклы нигез салган героик Кызыл Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты!

Немец оккупантларны тәмам тар-мар итү өчен алга!

3. Иптәшләр, кызылармеецлар, кызыл флотчылар, командирлар һәм политработниклар, партизаннар һәм партизанкалар! Сезнең өлешкә бөек азатлык бурычы төште. Бу бурычны үтәүгә лаеклы булыгыз,— немец-фашист кабахәтләрне рәхимсез рәвештә юк итегез!

4. Советлар Союзындагы барлык халыкларның уллары советлар ватаны өчен сугышка баралар. Яшәсен Кызыл Армия — СССР халыкларының туганлыгы һәм дуслыгы армиясе!

5. Кызыл Армиянең батыр сугышчылары! Ватаныбыз сезнең данлыклы җиңүләрегез белән горурлана! Немец-фашист юлбасарларны тагын да ныграк кыйнагыз! Туган җиребезне гитлерчы пычраклардан чистартыгыз!

6. Яшәсен, кол ителгән халыкларга азатлык китерүче һәм аларны Гитлер тираниясенә каршы көрәшкә рухландыручы Кызыл Армия!

7. Яшәсен Англия-Совет-Американың сугышчан союзының җиңүе, кешелек дөньясының явыз дошманнары — немец-фашист кол итүчеләрне җиңүе!

8. Немец-фашист басып алучыларга, аларның дәүләтенә, аларның армиясенә, аларның «Европада яңа тәртибенә» ләгънәт һәм үлем!

9. Кызыл Армия командирлары! Хәрби сәнгатьне тырышып үзләштерегез! Гаскәри частьларның һәм берләшмәләрнең сугышчан күнегүен туктаусыз күтәрегез, гаскәрләр төрләренең бергәләшеп хәрәкәт итүләре эшен бик яхшылап өйрәнегез, гаскәрләргә җитәкчелек итү мастерлары булыгыз!

10. Кызыл Армия сугышчылары! Үзегезнең коралыгызны бик яхшылап өйрәнегез, үз эшегезнең мастерлары булыгыз, немец-фашист басып алучыларны тәмам кырып бетергәнчегә кадәр нык кыйнагыз!

11. Кызыл Армия сугышчылары! Иң нык тәртип һәм тимердәй дисциплина — безнең дошманны җиңүебезнең шарты. Армиябездә дисциплинаны һәм тәртипне барлык чаралар белән ныгытыгыз!

12. Кызыл Армия сугышчылары! Немец фашистлары изүе астында ыңгырашучы миллионнарча совет кешеләре сезне үзләрен азат итүчеләр сыйфатында көтәләр. Совет җирен азат итү өчен көнбатышка таба, алга!

13. Шәһәрләребезне һәм авылларыбызны талаган һәм бөлдергән өчен, совет кешеләрен үтергән һәм немецларга кол итеп алып киткән өчен, хатын-кызларыбызны һәм балаларыбызны мыскыллаган өчен немец-фашист кабахәтләрдән үч алыйк!

Канга — кан! Үлемгә — үлем!

14. Кызыл Армия пехотачылары! Немецларны һәм аларның иярченнәрен совет җиреннән куыгыз! Дошман гаскәрләрен артларыннан куып барыгыз һәм кырыгыз! Немец басып алучыларны чолгап алыгыз һәм пленга алыгыз, әгәр дә пленга бирелүдән баш тартсалар, аларны юк итегез!

Яшәсен совет пехотачылары!

15. Совет очучылары—Ватаныбызның лачыннары! Һавада, җирдә һәм диңгездә дошманны рәхимсез тар-мар итегез!

Яшәсен совет очучылары!

16. Кызыл Армия танкистлары! Дошманны кыюлык белән юк итегез! Һөҗүмдә безнең пехотабызга булышлык итегез! Туган җиребезне немец басып алучылардан азат итегез!

Яшәсен совет танкистлары!

17. Кызыл Армия артиллеристлары һәм минометчиклары! Куәтле ут ударлары белән дошманның ныгытмаларын, каршылык күрсәтә торган үзелларын һәм терәк пунктларын җимерегез! Дошманның җанлы көчләрен һәм техникасын юк итегез!

Яшәсен совет артиллеристлары һәм минометчиклары!

18. Кызыл Армиянең механикалаштырылган частьларының һәм берләшмәләренең сугышчылары, командирлары һәм политработниклары! Дошман гаскәрләрен омтылышлы рәвештә куып барыгыз, кискен хәрәкәтләр белән чолгап алыгыз һәм тар-мар итегез!

Яшәсен Кызыл Армиянең механикалаштырылган частьлары һәм берләшмәләре!

19. Кызыл Армия кавалеристлары! Батыр казаклар, куркусыз егетләр! Дошман гаскәрләре сафларына кыюлык һәм кискенлек белән кисеп керегез, немец-фашист пычракларны юк итегез!

Яшәсен совет атлылары!

20. Хәрби Диңгез Флотының кызыл флотчылары, командирлары һәм политработниклары! Дошманга ударларны көчлерәк ясагыз! Дошман корабльләрен һәм транспортларын тар-мар итегез, гитлерчы басып алучыларны рәхимсезлек белән кырыгыз!

Яшәсен Совет моряклары!

21. Кызыл Армия автоматчиклары! Немец-фашист юлбасарларны ныграк кыйнагыз! Дошман өстенә автоматлардан ут яудырыгыз! Немецларга көндез дә, төнлә дә тынычлык бирмәгез!

Яшәсен Совет автоматчиклары!

22. Кызыл Армия разведчиклары! Немецлар тылында кыю хәрәкәт итегез! Дошманның урнашкан урынын һәм көчләрен эзләп табыгыз, аның ниятләрен һәм планнарын ачыгыз. Безнең гаскәрләрнең һөҗүме уңышлы чыгуга бөтен көчегез белән булышлык итегез!

Яшәсен куркусыз совет разведчиклары!

23. Кызыл Армия элемтәчеләре! Яхшы элемтә дошманны җиңүнең әһәмиятле шарты икәнлекне исегездә тотыгыз! Кызыл Армиядә элемтә эшен барлык чаралар белән яхшыртыгыз!

Яшәсен совет элемтәчеләре!

24. Инженерлык — сапер гаскәрләре сугышчылары, командирлары һәм политработниклары! Һөҗүм итеп баручы гаскәрләргә явыз дошманны тар-мар итүдә барлык средстволар белән булышлык итегез!

Яшәсен Кызыл Армиянең инженерлык — сапер частьлары!

25. Яшәсен безнең данлыклы пограничникларыбыз, совет чикләренең турылыклы сакчылары!

26. Кызыл Армиянең медицина работниклары! Врачлар, медсестралар, санитарлар! Исегездә тотыгыз, яраланган совет сугышчыларының тормышы һәм яңадан стройга кайтулары сезнең үз-үзегезне аямыйча эшләвегезгә бәйләнгән!

Яшәсен Кызыл Армиянең медицина работниклары!

27. Кызыл Армия гвардеецлары! Данлыклы гвардия байракларын намус белән йөртегез! Батырлык һәм геройлык, дисциплиналылык һәм нык торучанлык, һөҗүмдә омтылышлылык һәм көчле басым үрнәге булыгыз!

Яшәсен совет гвардиясе!

28. Ватаныбызның намусын, азатлыгын һәм бәйсезлеген батырларча саклаучы бөек ватан сугышы геройларына дан!

29. Яшәсен Кызыл Армиянең гаскәрләрне немец басып алучылар өстеннән җиңүгә алып баручы батыр генераллары!

30. Ленинградның, Одессаның, Севастопольнең һәм Сталинградның чын батырлык, тимердәй дисциплина, нык торучанлык һәм дошманны җиңә белү үрнәкләре күрсәткән героик сакчыларына дан!

31. Сталинград янында дошман гаскәрләрен чолгап алуны һәм бетерүне уңышлы рәвештә тормышка ашырган Кызыл Армиянең батыр сугышчыларына мактау һәм дан!

32. Ленинград блокадасын өзгән Кызыл Армия гаскәрләренә ялкынлы сәлам! Яшәсен ленинградлылар, ватаныбызның данлыклы патриотлары һәм патриоткалары!

33. Туганнар! Вакытлыча немец-фашист кабахәтләр изүе астында калган руслар, украинлылар, белоруслар, молдаваннар, литвалылар, латышлар, эстоннар, кареллар! Сезнең азатлык сәгатегез якынлаша. Фашист басып алучыларны рәхимсез кырыгыз, бөтен халыкның партизаннар хәрәкәте ялкынын көчәйтегез!

34. Совет партизаннары һәм партизанкалары! Дошманның тылларын туздырыгыз, аның штабларын юк итегез, тимер юлларны һәм күперләрне җимерегез, складларны һәм казармаларны яндырыгыз һәм шартлатыгыз, дошманның җанлы көчләрен кырыгыз! Һөҗүм итүче Кызыл Армиягә ярдәмегезне көннән-көн көчәйтегез!

Партизаннарыбызга һәм партизанкаларыбызга дан!

35. СССР гражданнарының һәм гражданкаларының гомуми хәрби өйрәнүләре безнең оборонабызны ныгыта. Совет патриотлары һәм патриоткалары! Сугыш эшен өйрәнегез! Ватанның оста сакчылары булыгыз!

36. «Бөтен көчебезне—героик Кызыл Армиябезгә, данлыклы Кызыл Флотыбызга ярдәмгә! Халыкның бөтен көче—дошманны тар-мар итүгә!» (Сталин).

37. Советлар Союзының хезмәт ияләре! Фронтовикларның семьялары турында кайгырту безнең Кызыл Армия турындагы бөтен кайгыртуыбызның яртысы булып тора. Ватаныбыз сакчыларының семьяларын гомуми игътибар һәм кайгыртучанлык белән чолгап алыйк!

38. Эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар, инженерлар һәм техниклар! Фронтка булышлык итү өчен җиң сызганып эшләгез! Һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиягә күбрәк танклар, самолетлар, орудиеләр, минометлар, снарядлар, миналар, пулеметлар, автоматлар, винтовкалар бирегез!

39. Колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар, МТС һәм совхоз эшчеләре һәм эшче хатын-кызлары! Немец изүчеләрне тар-мар итүдә Кызыл Армиягә булышлык итегез! Фронтка күбрәк азык бирегез! Бөтен көч—дошманны тар-мар итүгә!

40. Тимер юл транспорты работниклары! Тимер юлларның тотказсыз, төгәл эшләве өчен көрәшегез! Гаскәрләр һәм сугыш йөкләре төялгән транспортларны тиз үткәрүне оештырыгыз! Безнең гаскәрләрнең һөҗүме уңышлы булуны тәэмин итегез!

41. Совет интеллигенциясе! Совет учреждениеләре работниклары, инженерлар, укытучылар, агрономнар, врачлар, фән, сәнгать һәм әдәбият работниклары! Немец-фашист кол итүчеләргә каршы көрәшкә бөтен көчебезне һәм белемебезне бирик!

42. Кызыл Армия өчен танклар, самолетлар, орудиеләр төзүгә үзләренең акчаларын кертүче совет патриотларына һәм патриоткаларына кайнар сәлам!

43. Совет хатын-кызлары! Ирләр профессияләрен үзләштерегез, фронтка киткән ирләрне алмаштырыгыз! Һава һәм химия һөҗүменә каршы оборона эшен, санитария эшен, элемтәне өйрәнегез. Бөтен көчне—немец басып алучыларга каршы көрәшкә!

44. Совет егетләре һәм кызлары! Фронтка ярдәм итү өчен үз-үзегезне аямыйча эшләгез, производство техникасын үзләштерегез, хезмәт дисциплинасы үрнәкләре күрсәтегез, хәрби эшне бер туктаусыз өйрәнегез!

Яшәсен совет яшьләре!

45. Немец оккупантлардан азат ителгән шәһәрләрнең һәм авылларның хезмәт ияләре! Һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиягә бөтен көчегез белән булышлык итегез! Промышленностьны һәм авыл хуҗалыгын тизрәк аякка бастырыгыз!

46. Коммунистлар һәм комсомолецлар! Немец-фашист басып алучыларга каршы көрәшүчеләрнең беренче сафларында булыгыз!

47. Яшәсен данлыклы совет ватанының азатлыгы һәм бәйсезлеге!

48. Яшәсен Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе, немец-фашист басып алучыларны җиңү көрәшен оештыручы Ленин-Сталин Партиясе!

49. Немец оккупантларны тар-мар итү һәм аларны ватаныбыз чикләреннән куып чыгару өчен Ленин байрагы астында, Сталин җитәкчелегендә — алга!

БӨТЕНСОЮЗ КОММУНИСТЛАР (большевиклар) ПАРТИЯСЕ ҮЗӘК КОМИТЕТЫ.

ТАТАРСТАН АССР КОЛХОЗЛАРЫНДА ҺӘМ СОВХОЗЛАРЫНДА ТЕРЛЕКЧЕЛЕКНЕ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ПЛАНЫН ҮТӘҮНЕҢ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карары

«Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планын үтәүнең йомгаклары турында». Татарстан АССР Совнаркомы председателе иптәш С. Х. Гафиятуллин докладын тыңлап тикшергәннән соң, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы түбәндәгеләрне күрсәтеп үтә:

—СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының «Колхозларда җәмәгать терлекчелеген үстерү чаралары турында» 1939 нчы ел, 8 нче июль карарын һәм «Колхозларда һәм совхозларда яшь терлекләрне саклап калу һәм терлекләр санын арттыру чаралары турында» 1942 нче ел, 11 нче март карарын үтәү нәтиҗәсендә партия һәм совет оешмалары, җир органнары, колхозлар һәм совхозлар җәмәгать терлекчелеген үстерү өлкәсендә кайбер нәтиҗәләргә ирештеләр.

1942 нче елны Татарстан АССР колхозларында товарлыклы 789 яңа терлекчелек фермасы оештырылды һәм хәзер, уртача алганда, һәрбер 100 колхозга 100 товарлыклы сөтчелек фермасы, 100 товарлыклы сарык асраучылык фермасы һәм 81 товарлыклы дуңгыз асраучылык фермасы туры килә; колхозларда продукт бирүче терлекләр саны мөгезле эре терлекләр буенча 22,3 процентка, дуңгызлар буенча 14,9 процентка һәм сарыклар буенча 13,4 процентка артты.

Фронтка һәм илгә тагын да күбрәк икмәк, ит һәм промышленность өчен чимал бирү турында халыклар юлбашчысы иптәш Сталинның күрсәтмәсен үтәп, Татарстан АССР колхозлары 1942 нче елны ит тапшыру буенча еллык планны 104,7 процент итеп үтәделәр.

Ширәмәт районы колхозлары мөгезле эре терлекләр буенча дәүләт планын 110 процент итеп, Әгерҗе районында 109,1, Калинин районында 102,5, Мөслим районында 101,6, Минзәлә районында 100,4 процент үтәделәр.

Ләкин Татарстан АССР буенча гомумән алганда колхозларда һәм совхозларда терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планы терлекләрнең бер генә төре буенча да үтәлмәде һәм терлекчелек эше әле һаман да таркау хәлдә калуында дәвам итә.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, колхозларда ана терлекләр буенча билгеләнгән минимум — җәмәгать терлекчелеген тагын да үстерүнең бу нигезе үтәлмәгәнлеген, ә Кайбыч, Алексеевский, Кама тамагы, Бөгелмә һәм башка кайбер районнарда ана терлекләр санының хәтта кимегәнлеген әйтеп үтә.

Республиканың совхозларында терлекчелекне үстерү эше гадәттән тыш начар тора.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, колхозларда һәм совхозларда терлекчелекне үстерү эшендә төп кимчелекләр терлек азыгы базасы булдыруга бәя биреп җиткермәүдән, терлек азыгы культураларының уңышы түбән булудан, терлекләрне начар тәрбияләүдән, чаптыру кампаниясе планын үтәмәүдән, ана терлекләрнең күп санда кысыр калуларына һәм абортларына юл куелудан, яраклы терлекләр тууының аз булуыннан, үлүнең күп булуыннан, терлекләрне әрәм-шәрәм итүдән һәм дуңгыз һәм вак терлекләр (йорт кошлары, йорт куяннары) үстерүгә игътибар бирмәүдән гыйбарәт дип саный.

1942 нче елны колхозларда һәм совхозларда контроль булмау һәм терлекчелеккә тиешенчә игътибар бирелмәү аркасында терлекләрнең күп санда үлүенә һәм әрәм-шәрәм ителүенә юл куелган. Бу хәл куркынычлы күләмнәргә кадәр барып җиткән. Акташ, Яңа Чишмә, Кайбыч, Лаеш, Мамадыш, Бөгелмә, Заинск районнарында, Актаныш, Алабуга, «Комсомолец», «МЮД», «Пятилетка» совхозларында терлекләрнең аеруча күп үлүенә юл куелган.

Терлекләрнең продукт бирүе елдан-ел кими. Республиканың колхозларында 1942 нче елны һәрбер фураж сыерыннан алынган сөт 1941 нче елгы 1.040 литр урынына бары 805 литр гына булган, сөт тапшыру планы 41,2 процентка гына үтәлгән; Молсемтрест совхозларында 1942 нче елны һәрбер фураж сыерыннан 1941 нче елгы 1.749 литр урынына 1.143 литр сөт савып алынган, сөт тапшыру планы бары 58,5 процент кына үтәлгән.

Республиканың күп кенә колхозларында һәм совхозларында терлекләрне кырда йөртеп һәм урында ашатып симертү оештырылмаган: Бу хәл ит тапшыру исәбенә күп санда түбән кондицияле терлекләр һәм шактый санда яшь терлекләр тапшыруга китергән, шуның нәтиҗәсендә колхозлар һәм совхозлар уннарча мең баш терлекләрне файдасызга тотканнар.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, ВКП(б) ның күп кенә райкомнарының, район башкарма комитетларының, Татарстан АССР Наркомземының, район җир бүлекләренең, МТС һәм совхоз директорларының һәм политбүлек начальникларының атлар санын арттыру һәм аларны саклап калу эше белән гадәттән тыш начар шөгыльләнүләрен аеруча күрсәтеп үтә. Республика колхозларының һәм совхозларының күпчелегендә эш атларын тәрбияләү һәм алардан производствода дөрес файдалану әле хәзергә кадәр оештырылмаган, бу хәл нәтиҗәдә бик күп атларның ябыгып калуына, корчангы белән авыруларына һәм сафтан чыгуларына сәбәп булган.

Күп кенә районнарда (Алексеевский, Бөгелмә, Кама тамагы, Кайбыч, Яңа Писмән, Акташ) барлык төр терлекләрне тәрбияләү буенча зоотехника һәм ветеринария кагыйдәләренең тормышка ашырылуы һич тә канәгатьләнерлек түгел, карантин чаралары тупас рәвештә бозыла, терлекләрне тәрбияләүдә нясезлек бетерелмәгән, терлекчелек һәм ветеринария биналары төзү планы үтәлмәгән.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, партия, совет оешмаларының, Татарстан АССР Наркомземының, район җир бүлекләренең, МТС һәм совхоз директорларының һәм политбүлек начальникларының канәгатьләнерлек эшләмәүләре нәтиҗәсендә республика колхозларының һәм совхозларының шактый өлешендә терлекчелек кадрлары әзерләү планының үтәлмәгәнлеген, әзерләнгән работникларны үз эшләрендә файдаланмауларын, күп кенә хәлләрдә терлекчелек эшендә бернинди дә ышаныч казана алмаслык кешеләр эшләүне әйтеп үтә.

Терлекләрнең продукт бирүен арттырган өчен колхозчыларга өстәмә түләү турындагы закон вакытында тормышка ашырылмый, колхозларның күпчелегендә производство заданиеләре терлекчелек бригадаларына һәм үзләренә беркетелгән терлекләр группалары буенча колхозчыларга еш кына җиткерелми кала, заданиеләрнең үтәлүен учетка алу һәм тикшерү начар куелган.

Республиканың фәнни-тикшерү учреждениеләре үзләренең көндәлек эшләрен колхозларның һәм совхозларның ихтыяҗларына һәм таләпләренә бәйләп алып бармыйлар, терлекчелек буенча алдынгылар тәҗрибәсен туплау белән йомшак шөгыльләнәләр һәм терлекчелек кадрларының квалификациясен күтәрүдә, терлекләрнең продукт бирүен арттыруда, сәламәтләндерү чаралары үткәрүдә колхозларга һәм совхозларга кирәкле ярдәмне күрсәтмиләр.

Өлкә Комитеты пленумы Татарстан АССР Наркомземының (терлекчелек буенча нарком урынбасары иптәш Сливовский) гадәттән тыш начар эшләвен, терлекчелек эшенә өстән генә җитәкчелек итүен, конкрет төстә җитәкчелек итмәвен аеруча күрсәтеп үтә.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, Татарстан АССР да терлекчелекнең мондый гафу ителмәслек хәлдә булуы ВКП(б) ның күп кенә райкомнарының, район советлары башкарма комитетларының, район җир бүлекләренең, совхозлар трестлары директорларының (Дубей һәм Урманов иптәшләр), МТС һәм совхоз директорларының һәм политбүлек начальникларының әле хәзергә кадәр сугыш шартларыннан үзләре өчен кирәкле нәтиҗәләрне ясамауларыннан, терлекчелек эшенә канәгатьләнерлек җитәкчелек итмәүләреннән, терлекчелек мәсьәләләре буенча СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел, 8 нче июньдә, 1941 нче ел, 14 нче мартта һәм 1942 нче ел, 11 нче мартта чыгарган гаять әһәмиятле карарларын тулысынча тормышка ашыруны тәэмин итмәүләреннән килеп чыккан дип саный.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карар бирә:

1. ВКП(б) райкомнарын, район советлары башкарма комитетларын, Татарстан АССР Наркомземын, совхозлар трестлары директорларын, политсектор начальникларын, МТС һәм совхоз директорларын һәм политбүлек начальникларын, колхоз председательләрен һәм партиянең башлангыч оешмаларын,— терлекчелек өлкәсендә югарыда әйтелгән кимчелекләрне бетерү буенча конкрет чаралар күрергә һәм республикадагы һәрбер колхозның һәм совхозның терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планын һичбер сүзсез үтәүләрен, терлекләрнең продукт бирүен арттыруларын, терлекчелек продуктлары буенча мәҗбүри тапшыруларның үтәлүен һәм 1943 нче елны ныклы терлек азыгы базасы булдыруны тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

2. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, колхозларда җәмәгать терлекчелеген үстерү эшенә партия, совет оешмалары һәм җир органнары җитәкчеләренең, бигрәк тә Кайбыч, Бөгелмә, Алексеевский, Кама тамагы, Әлки һәм Тәмте районнарында, әһәмият биреп җиткермәүләре кебек яраксыз практиканы гаепли һәм ВКП(б) райкомнары секретарьларыннан, район советлары башкарма комитетлары председательләреннән, МТС һәм совхоз директорларыннан һәм политбүлек начальникларыннан җитәкчелекне кискенлек белән яхшыртуны, колхозларда һәм совхозларда терлекчелекне үстерү ягыннан булган хәзерге кимчелекләрне кичекмәстән төзәтүне таләп итә.

3. Татарстан АССР Наркомземын, совхозлар трестларын, ВКП(б) райкомнарын, район советлары башкарма комитетларын, МТС һәм совхоз директорларын һәм политбүлек начальникларын, район җир бүлекләрен түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) барлык колхозларда һәм совхозларда терлекләрнең нинди шартларда кышлауларын 10 көн срок эчендә тикшереп чыгарга, ашату нормаларын, терлек азыкларыннан файдалану тәртибен һәм бу азыкларны ашату өчен әзерләүне (саламны кисүне, печән онын ваклауны, пешекләүне, яшь терлекләргә эчертү өчен печән суы әзерләүне һ. б.) билгеләргә, яшь терлекләргә, урчеткечләргә һәм буаз терлекләргә иң яхшы сыйфатлы азыклар ашатуны тәэмин итәргә;

б) су баса торган урыннардагы печәнне 15 нче марттан соңга калмыйча ташып бетерергә һәм язгы юл өзеклеге чорына ике айлык терлек азыгы запасы әзерләп куярга;

в) 1943 нче елга ветеринария-санитария, профилактика чаралары планын 5 нче мартка төзергә һәм һәрбер колхозга һәм совхозга җиткерергә, аларның үтәлүенә бик нык контроль куярга;

г) һәрбер терлекнең үлүе, имгәнеп авыруы, аборты һәм бияләрнең, сыерларның, дуңгызларның, сарык һәм кәҗәләрнең чаптырылмый калуы фактын тикшерергә һәм, гаепле кешеләрне җавапка тартып, җәмәгать терлекчелеген какшатучы дип карап, килгән зыянны алардан түләтергә;

д) яшь терлекләрне саклап калу өчен көрәшү максаты белән терлекләрнең бала тудырулары вакытына төнге дежурстволар оештырырга, фермадагы барлык терлекләр бөтен тәүлек буена контроль астында булырга тиешләр;

е) терлекчелек фермаларын иң яхшы колхозчылар һәм совхоз эшчеләре белән ныгытырга; бу эшне 15 нче мартка кадәр тәмам итәргә, терлекләрне саклап калу һәм аларның продукт бирүен арттыру турыдан-туры, фермада сөт савучы, бозау караучы, дуңгыз асраучы, бригадир һәм ферма мөдире булып кем эшләүгә бәйләнгәнлекне күздә тотып, терлекчелек работникларын кимендә 2—3 елга даими эшкә беркетергә;

ж) барлык колхозларда һәм совхозларда терлекчелек кадрлары арасында зоология-ветеринария укулары оештырырга, укытучылар итеп район җир бүлекләренең, совхозларның, башка учреждениеләрнең зоология-ветеринария работникларын, фермаларның терлекчелек буенча эшләүдә тәҗрибәләре һәм практик күнекмәләре булган иң яхшы работникларын тартырга, өйрәнүчеләрне аерым белгечләргә беркетү юлы белән индивидуаль өйрәтүне киң күләмдә кулланырга;

з) терлекчелек кадрлары әзерләү планын тулысынча үтәргә һәм 1943 нче елны һәрбер колхозның үзенең ветеринария фельдшеры яки ветеринария санитары булырлык хәлгә ирешергә;

и) терлекчелек фермаларында бөтен эшне терлекләрнең продукт

(Ахыры 3 нче биттә).

ТАТАРСТАН АССР КОЛХОЗЛАРЫНДА ҺӘМ СОВХОЗЛАРЫНДА ТЕРЛЕКЧЕЛЕКНЕ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ПЛАНЫН ҮТӘҮНЕҢ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының XI нчы пленумы карары

(Башы 2 нче биттә).

бирүен арттырган өчен хезмәткә өстәмә түләү турында СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарына туры китереп оештырырга, яшь терлекләр алу, яшь терлекләрнең тәүлеклек уртача авырлык үлчәвен арттыру, йон алу, сөт алу, терлекләрне симертү буенча индивидуаль заданиеләр билгеләргә, һәрбер колхозда учетны төгәл итеп куюны һәм колхозчыларга өстәмә түләү тәртибендә тиеш булган продукцияне вакытында түләүне тәэмин итәргә.

4. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы Әлки, Кукмара һәм башка кайбер район җитәкчеләренең әле хәзергә кадәр дуңгыз асраучылык фермалары оештыруга, вак терлекчелекне үстерүгә бәя бирел җиткермәүләрен бөтенләй гафу ителмәслек дип саный һәм түбәндәгеләрне таләп итә:

а) колхозларда җәмәгать терлекчелеген тизрәк үстерү һәм 1943 нче елның җәендә дәүләтне ит белән тәэмин итү өчен, дуңгызларның иң тиз үсүче һәм иң күп үрчүче терлекләр икәнлеген искә алып, һәрбер колхозда дуңгыз асраучылык фермалары оештырырга;

б) һәрбер колхозда кимендә 300—500 баш тавыгы булган ферма оештырырга, су кошлары үрчетү эшен киң күләмдә җәеп җибәрергә;

в) һәрбер колхозда кимендә 15-25 ана куяннан товарлыклы куян асраучылык фермасы оештыруны яхшы һәм кирәкле дип санарга;

г) фермаларга ана терлекләрне тизрәк туплау максаты белән, көтүләрне яхшырту өчен яраклы булган барлык бозауларны тулысынча саклап калу чараларын күрергә; шушы елның 1 нче июненнән соңга калмыйча, ана терлекләр санын тулыландыру һәм аларның сыйфатын яхшырту өчен җитәрлек кадәр санда яшь бәрәннәр һәм дуңгыз балалары сайлап алырга;

д) шушы елның 1 нче мартына кадәр үрчеткечләр һәм ана терлекләр сайлап алуны тәмам итәргә, терлекләрнең барлык төрләре буенча барлык ана терлекләрне чаптыру планын тулысынча үтәрлек итеп, аларны тиешенчә әзерләүне тәэмин итәргә;

е) колхозчыларның, эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең яшь терлекләренә, бозауларына һәм сарык бәрәннәренә кичекмәстән контрактация ясарга керешергә һәм 1943 нче елны аларны тулысынча алуны тәэмин итәргә;

ж) һәрбер колхозның һәм совхозның ит тапшыру планын үтәвен тәэмин итү өчен ит тапшыру заданиесен тулысынча капларлык күләмнәрдә терлекләрнең махсус симертелгән группаларын булдырырга.

5. Шушы елның 15 нче мартыннан соңга калмыйча һәрбер колхоз һәм совхоз буенча терлекләрнең биналар белән тәэмин ителүен тикшерүне тәмам итәргә, аларның нинди хәлдә булулары турында тиешенчә акт төзергә һәм терлекчелек биналары белән тәэмин ителмәгән барлык колхозларда һәм совхозларда төзелеш площадкасына кирәкле материалларны кичекмәстән әзерләүне һәм китерүне оештырырга, 1943—1944 нче елгы кышка республикадагы һәрбер колхоз һәм совхоз яраклы җылы биналар белән тәэмин ителерлек итеп, төзү бригадалары оештырырга.

6. Колхозларда һәм совхозларда ныклы терлек азыгы базасы булдыру һәм терлек азыгы культураларының уңышын кискенлек белән арттыру өчен Татарстан АССР Наркомземын, совхозлар трестларын, МТС һәм совхоз директорларын, район советлары башкарма комитетларын, ВКП(б) райкомнарын һәм колхоз правлениеләрен,—1943 нче елны терлек азыгы һәм силос культуралары чәчү һәм силослау планнарын тулысынча үтәргә, болын-көтүлек хуҗалыгын тамырыннан яхшыртырга, колхозларның барлык болыннарын һәм көтүлек җирләрен кырчылык бригадаларына, ә бригадалар эчендә звеноларга беркетергә мәҗбүр итәргә.

7. Җәмәгать терлекчелеген үстерү планын уңышлы үтәү эшендә колхозларга һәм совхозларга чын булышлык күрсәтү өчен Татарстан АССР Совнаркомы председателе урынбасары иптәш Г. С. Семеновка, Наркомзем белән берлектә, 10 көн срок эчендә, үзләренең белгечлекләре буенча эшләмәүче барлык терлекчелек белгечләрен учетка алырга һәм аларны колхозларга һәм совхозларга даими эшкә җибәрергә тәкъдим итәргә.

8. Татарстан АССР җир эшләре халык комиссары иптәш Хөсәеновка, авыл хуҗалыгы вузлары һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре директорлары белән берлектә, 10 көн срок эчендә, терлекчелек өлкәсендә республиканың колхозларына һәм совхозларына вузларның һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләренең, артта калучы районнарга кичекмәстән иң яхшы белгечләрне җибәрү юлы белән, практик булышлык күрсәтүләре буенча план төзергә тәкъдим итәргә.

* * *

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы барлык партия, комсомол, совет оешмаларыннан һәм җир органнарыннан, шулай ук колхозлардагы һәм совхозлардагы башлангыч партоешмалардан һәм комсомол оешмаларыннан терлекчелек эшенә җитәкчелекне кискенлек белән яхшыртуны, колхозларда һәм совхозларда массовый-политик эшне көчәйтүне, социалистик ярышны киң күләмдә җәелдерүне, алдынгылар тәҗрибәсен барлык чаралар белән популярлаштыруны һәм социалистик терлекчелекне үстерү өлкәсендә партия һәм хөкүмәт куйган бурычларны уңышлы үтәүгә барлык колхозчыларны, колхозчы хатын-кызларны һәм совхоз эшчеләрен туплауны таләп итә.

Партиянең Татарстан оешмасының үсеше турында

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карары

13—16 февраль, 1943 ел.

«Партиянең Татарстан оешмасының үсеше турында» ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Х. М. Пазиков докладын тыңлап тикшергәннән соң, ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы түбәндәгеләрне күрсәтеп үтә: Партиянең Татарстан оешмасы, совет халкының бөек юлбашчысы һәм полководецы иптәш Сталинның тарихи күрсәтмәләре белән коралланып, ватан сугышы көннәрендә ВКП(б) сафларына эш ягыннан һәм политик яктан тикшерелгән иң яхшы кешеләрне сайлап алу буенча үзенең эшен шактый яхшыртты.

Большевиклар партиясенең һәм бөек Сталинның даһи җитәкчелегендә Кызыл Армия Гитлер урдаларына сугышлар тарихында тиңдәше булмаган җимергеч ударлар ясый: Сталинград янында Гитлерның 300.000 нән артык кешедән торган, сайлап алынган армиясе тулысынча тар-мар ителде, ватан сугышының башка фронтларында да безнең частьларның уңышлы һөҗүме бара.

Болар барысы да совет халкы каршында большевиклар партиясенең дәрәҗәсен тагын да күтәрделәр, хезмәт ияләрен партия тирәсенә тагын да тупладылар, аның масса белән элемтәсен ныгыттылар. Моны илдә гаять зур патриотлык күтәрелеше, эшчеләрдән, крестьяннардан һәм интеллигенциядән иң яхшы кешеләрнең ВКП(б) сафларына өзлексез агылып торуы раслый. Ватан сугышы башланганнан бирле (1941 нче елның 1 нче июленнән 1943 нче елның 1 нче январена кадәр) партиянең Татарстан оешмасы ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 5.118 кеше һәм ВКП(б) га член итеп 4.367 кеше кабул итте. ВКП(б) га яңа алынучылар арасында хатын-кызлар 44,3 процент.

Ләкин ВКП(б) ның күп кенә райкомнарының һәм шәһәр комитетларының партия-масса эшен йомшак алып барулары, партия сафларына алуга тиешенчә игътибар бирмәүләре нәтиҗәсендә партиянең Татарстан оешмасының үсеше, бигрәк тә производство эшчеләре һәм колхозчылар исәбенә үсүе, җитәрлек түгел. (Ленин, Сталин, Биектау, Куйбышев, Яна Чишмә, Балык бистәсе, Лаеш, Кама тамагы, Чепья, Әтнә райкомнары).

Шулай ук өлкә комитеты пленумы партиянең кайбер оешмаларында (Тельман, Куйбышев, Киров, Красный бор һ. б.) җирле халыктан—татарлардан ВКП(б) сафларына член һәм кандидатлар сайлап алу эше йомшак оештырылганлыкны күрсәтеп үтә.

ВКП(б) ның кайбер райкомнары ВКП(б) сафларын тулыландыру өчен резерв булу ягыннан комсомолның роленә әле һаман да бәя бирел җиткермиләр. Кайбер районнарда партиягә яңа алынучылар составында комсомолецларның бик аз булуын шуның белән генә аңлатырга мөмкин.

Киров, Югары Ослан, Юдино һәм башка районнарда партиягә алган чакта индивидуаль тәртиптә сайлап алу принцибын бозу фактлары булган һәм шуның нәтиҗәсендә ВКП(б) сафларына лаексыз кешеләр алынган. Бюрократизм һәм волокита фактлары бар (гаризаларны тикшерүне озакка сузу, партия документлары бирүгә тоткарлык ясау һ. б.).

Өлкә Комитеты пленумы күп кенә МТС политбүлекләренең колхозлардагы партия оешмаларын ныгыту мәсьәләләре белән, авылда партия-масса эшен яхшырту белән канәгатьләнерлек шөгыльләнмәүләрен, колхоз активы белән тәрбия эше алып бармауларын, тикшерелгән, алдынгы кешеләрне партиягә сайлап алуда партиянең башлангыч оешмаларына йомшак булышлык итүләрен аеруча күрсәтеп үтә. Политбүлекләр партия сафларын МТС лардагы җитәкче профессияләр эшчеләре исәбенә, тракторчылар, комбайнчылар һ. б. исәбенә үстерүгә тиешенчә игътибар бирмиләр (Чүпрәле, Куйбышев, Трехозерский МТС лары).

Пленум, ВКП(б) сафларына яңа алынучылар белән эшләү түбән дәрәҗәдә тора, дип саный. ВКП(б) райкомнары һәм шәһәр комитетлары яшь коммунистларны тәрбияләү белән чиктән тыш аз шөгыльләнәләр, партия укуларын оештырмаганнар, аларны җәмәгать-политик эшкә йомшак тарталар.

Партиянең күп кенә оешмаларында коммунистик тәрбия мәктәбе сыйфатында партия җыелышларының роле һәм әһәмияте түбәнәйтелгән. Партиянең ачык җыелышлары чиктән тыш сирәк үткәрелә. Җыелышлар начар әзерләнәләр, мәсьәләләрне тикшерүдә коммунистларның катнашуы җитәрлек дәрәҗәдә актив түгел.

Партия оешмаларының шактый өлешендә партия членнары һәм кандидатлары арасында тәрбия эшенең йомшак булуы—мондый оешмаларда партия уяулыгының йомшавы, коммунистларның дисциплинасызлыгы, көнкүрештә череп таркалу һәм партия тормышыннан аерылу фактлары булуның төп сәбәпләренең берсе.

Болар барысы да ВКП(б) ның кайбер райкомнарының һәм аларның җитәкчеләренең бөек ватан сугышы шартларында партия оештыру эшенең әһәмияте үлчәүсез дәрәҗәдә үскәнлекне аңламауларын, хуҗалык һәм партия-политик эшне бергә бәйләп бара белмәүләрен, партиянең башлангыч оешмаларына йомшак җитәкчелек итүләрен, аларны үстерү һәм оешу ягыннан ныгыту турында кайгыртмауларын күрсәтәләр.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карар бирә:

Партиянең шәһәр комитетларын һәм райкомнарын,—ВКП(б) сафларына кабул итүне оештыруда булган кимчелекләрне бетерергә, партия-оештыру, масса-политик эшне тамырыннан яхшыртырга мәҗбүр итәргә. Моның өчен:

1. Партиянең башлангыч оешмаларын оешу ягыннан ныгыту турында, аларның эшен барлык чаралар белән яхшырту турында көн саен кайгыртырга, барлык коммунистларның эштә актив катнашуларына, партиянең һәрбер оешмасының хуҗалык-политик бурычларны төгәл һәм вакытында үти алырлык, сугышчан тупланган коллектив булуына ирешергә.

2. Һәрбер предприятиедә, совхозда, МТС та һәм колхозда активны

(Ахыры 4 нче биттә).

Партиянең Татарстан оешмасының үсеше турында

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карары

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

үстерү һәм тәрбияләү буенча системалы эш алып барырга, аны җәмәгать-политик эшкә тартырга, Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән иң яхшы, совет патриотларын ВКП(б) сафларына сайлап алырга.

3. Пленум ВКП(б) райкомнарын һәм шәһәр комитетларын ВКП(б) уставын, индивидуаль тәртиптә сайлап алу принцибын төгәл үтәргә, ВКП(б) сафларына практик эштә тикшерелгән, партия эшенә чын күңелдән бирелгән алдынгы эшчеләрне, крестьяннарны, интеллигенцияне алырга мәҗбүр итә.

4. Җитәкче профессия эшчеләрен, турыдан-туры производствода эшләүче колхозчыларны, шулай ук комсомолецларны, хатын-кызларны һәм җирле халыкларны—татарларны партиягә тартуга аеруча игътибар бирергә.

5. Пленум ВКП(б) членлыгына кандидатлар белән эшләүне тамырыннан яхшыртуны, аларның кандидат булып яшәүләренең озакка сузылуының сәбәпләрен өйрәнүне, ВКП(б) членлыгына керү өчен аларны әзерләү эшендә аларга практик ярдәм оештыруны таләп итә. ВКП(б) га яңа алынганнарны тәрбияләүне яхшыртырга, һәрбер коммунистның әзерлек дәрәҗәсенә карап, ВКП(б) уставын, программасын һәм тарихын өйрәнүләрен оештырырга, яшь коммунистларны партия һәм җәмәгать эшенә актив тартырга, партия порученнеләре бирергә, үтәлешне һәрвакыт тикшереп торырга.

6. Партия җыелышларын регуляр рәвештә үткәрергә, партия членнарына һәм кандидатларына большевистик тәрбия бирү мәктәпләре сыйфатында аларның ролен күтәрергә, җыелышларны җентекләп һәм вакытында әзерләргә, партия җыелышларына куелган мәсьәләләрне тикшерүдә коммунистларның актив катнашуын тәэмин итәргә, партия оешмаларының һәм аерым коммунистларның эшендәге кимчелекләрне большевикларча тәнкыйть итүне барлык чаралар белән җәелдерергә, партиянең эчке демократиясен бозу фактларына юл куймаска.

7. Аерым коммунистлар арасында булган дисциплинасызлыкка һәм таркаулыкка каршы кискен көрәш алып барырга, партия оешмаларының һәм аерым коммунистларның партия органнарының карарларын, директиваларын һәм партия порученнеләрен үтәмәскә маташуларын бетерергә.

ВКП(б) Өлкә Комитеты Пленумы ВКП(б) ның барлык членнарына һәм кандидатларына, безнең партиябезнең көче һәм куәте, барыннан да элек, ныклы дисциплинада, партия, дәүләт һәм хезмәт дисциплинасында икәнлекне аеруча аңлатып үтә. Дисциплинаны, бигрәк тә хәзер, ватан сугышы шартларында, барлык чаралар белән ныгытырга кирәк.

8. Пленум МТС политбүлекләре начальникларыннан ВКП(б) Үзәк Комитетының «МТС ларда һәм совхозларда политбүлекләр оештыру турында» гы карарын тайпылышсыз үтәүне таләп итә. Бу карарда болай диелгән: «Машина-трактор станцияләре эшли торган районда МТС политбүлекләре колхозларның партия һәм комсомол оешмаларына көндәлек ярдәм күрсәтәләр, аларга инструкцияләр бирәләр, аларның эшләрен тикшерәләр һәм үзләренең бу эшләрен бөтенесен дә партия райкомы белән элемтәдә булган хәлдә үткәрәләр».

Пленум МТС һәм совхоз политбүлекләрен партиянең башлангыч оешмаларын ныгыту һәм үстерү буенча, партиясез активны тәрбияләү буенча, колхозлардагы, совхозлардагы һәм МТС лардагы иң яхшы кешеләрне ВКП(б) сафларына тарту буенча үзләренең эшләрен кискенлек белән яхшыртырга мәҗбүр итә.

9. Партиянең башлангыч оешмалары секретарьларының күпчелеге җитәкчелек эшенә беренче тапкыр гына килгәнлектән һәм партия эшендә тәҗрибәләре булмаганлыктан, Өлкә Комитеты пленумы партия райкомнарын һәм шәһәр комитетларын алар өчен партия эше мәсьәләләре буенча даими семинарлар оештырырга, партиянең башлангыч оешмаларының җитәкчеләренә ВКП(б) райкомнары һәм шәһәр комитетлары секретарьларының, шулай ук бюро членнарының турыдан-туры булышлык итүләрен тәэмин итәргә мәҗбүр итә.

ВКП(б) райкомнары һәм шәһәр комитетлары инструкторларының партия аппаратында үзәк фигура сыйфатында ролен һәм әһәмиятен күтәрергә.

* * *

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы партиянең барлык оешмаларын, барлык коммунистларны партия-оештыру һәм политик-масса эшен сугыш заманы бурычлары дәрәҗәсенә күтәрергә, партия сафларын туктаусыз ныгытырга һәм чыныктырырга, Ленин—Сталинның бөек эшенә чын күңелдән бирелгән алдынгы кешеләрне ВКП(б) га кабул итү турында көн саен кайгыртырга чакыра.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— Соңгы ике атна эчендә немецлар Норвегиянең төрле шәһәрләрендә 500 дән артык кешене кулга алганнар. Грини концентрация лагереннан һәм Меллергатен (Осло) төрмәсеннән 153 норвегияле Германиягә мәҗбүри эшләргә озатылган.

— 14 нче февральдә Бельгиядә ике бельгияле фашист үтерелгән. Соңгы көннәрдә Бельгия патриотлары немецлар белән бергә эш итүче хыянәтчеләрдән 30 кешене юк иткәннәр.

— Румыния властьлары Германиягә җибәрү өчен крестьяннарның авыл хуҗалыгы продуктларын масса төсендә тартып алалар.

— 14 нче февральгә каршы төндә Парижда Германиянең 2 офицеры авыр яраланган. Шушы уңай белән Германиянең оккупация властьлары барлык ресторannарны һәм кафеларны 8 көнгә япканнар.

— Голландия патриотлары немецлар тарафыннан билгеләнеп куелган бургомистр Утрехтны үтергәннәр.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР КРАСНОГРАД ҺӘМ ПАВЛОГРАД ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

20 нче февральдә УКРАИНАДА, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, Көньяк-Көнбатыш фронты гаскәрләре КРАСНОГРАД шәһәрен һәм тимер юл узелын, ПАВЛОГРАД шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

20 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

20 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че берләшмәнең частьлары дошман тарафыннан көчле итеп ныгытылган халык яши торган 3 пунктны алдылар. Бу оборона чиге өчен булган сугышларда немецларның 200 дән артык солдат һәм офицерлары, 13 танклары һәм 5 автомашиналары юк ителде. Инженерлык милекләре төялгән 18 автомашина кулга төшерелде.

* * *

Ровенькидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Моторлаштырылган Н-че часть бик каты сугыш нәтиҗәсендә халык яши торган зур пунктны алды. 14 орудие, 19 пулемет һәм берничә сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар гитлерчыларның контратакаларын кире кайтарып, немецларның 8 танкысын җимерделәр һәм яндырдылар, дошманның бер ротага якын пехотасын кырдылар.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Люботин районында немецларның бер полкка якын пехотасы, 16 танкысы, 150 автомашинасы һәм 13 самоход орудиесе юк ителде. Икенче бер участокта безнең танкистлар немецларның 9 танкысын, 39 автомашинасын һәм танкка каршы ата торган 8 орудиесен юк иттеләр. Трофейлар, шул исәптән 4 авыр орудие, кулга төшерелде.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең частьлар гитлерчыларның контратакаларын кире кайтардылар, ә көчләрнең бер өлеше белән алга киттеләр. Н-че часть төнге сугышта немецларның 300 гә якын солдат һәм офицерларын кырып ташлады. 12 миномет, 16 пулемет, бик күп винтовкалар һәм 3 радиостанция кулга төшерелде. Икенче бер участокта немецлар безнең частьларга контратака ясадылар. Пулеметчик кече сержант иптәш Шлюхин дошманның флангысына барып чыкты һәм кинәт ут ачып немецларның берничә дистә солдат һәм офицерларын кырып ташлады. Гитлерчыларның калганнары тәртипсез рәвештә чигенделәр.

* * *

Краснодардан көнбатыштарак безнең гаскәрләр халык яши торган күп кенә зур пунктларны алдылар. Дошман, совет частьларының алга баруын тоткарларга маташып, яңа оборона линияләре төзеде һәм мина кырлары ясады. Совет сугышчылары омтылышлы атака белән дошманның оборона линиясен өзделәр һәм алга бардылар. Безнең очучылар һава сугышларында немецларның 9 самолетын атып төшерделәр.

* * *

Орел өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз, дошманның җанлы көчләре төялгән 4 вагон һәм орудиеләр, автомашиналар төялгән 7 вагон җимертелгән. Орел партизаннарының икенче бер отряды бик каты сугышларда дошманның йөзгә якын солдат һәм офицерларын кырган. Партизаннар зур трофейлар кулга төшергәннәр.

* * *

Немецларның 166 нчы марш батальоны солдаты пленный Эрих Фунфаш түбәндәгеләрне сөйләде: «Безнең батальон Франциядә тора торган төрле частьлардан чакыртып алынган солдатлардан төзелде. 14 нче январьда без поездга утырып Варшавага чыгып киттек. Шуннан батальонны Курскига җибәрделәр. Безгә килеп житү белән командованиенең, Курск бик көчле итеп ныгытылган һәм ул нинди генә шартларда да калдырып кителмәскә тиеш, дигән приказын укыдылар. Ләкин икенчеме яки өченчеме көнне ук паника башланды. Күрәсең, руслар оборонаны өзгәннәр икән. Барлык складлар һәм милекләр ташлап калдырылды. Батальонның күп кенә солдатлары качып киттеләр һәм пленга эләктеләр».

* * *

Краснодар краеның Тверская станицасында торучылар немец-фашист кеше ашаучыларның колхозчы Багдасар Шабарян семьясын ничек җәзалаулары турында тулы мәгълүматлар сөйләделәр. Бер группа немец солдатлары Шабарянның өенә бәреп кергәннәр һәм сөт таләп иткәннәр. Гарпина Шабарян, балалар өчен генә бик аз сөт калды һәм мин аны бирә алмыйм, дип белдергән. Котырынган бандитлар бөтен семьяны: 80 яшьлек Багдасар Шабарянны, 70 яшьлек Гарпина Шабарянны, 47 яшьлек Арут Шабарянны, кече яшьтәге балалардан Аршакны, Валентинны, һәм Владимирны атып үтергәннәр. Гитлерчылар Шабаряннар семьясын станицада торучы барлык халыкның күз алдында атканнар.

ГИТЛЕРЧЫ ИДАРӘЧЕЛӘР БОРЧЫЛАЛАР

Берлинда Геббельсның чыгышы

ЖЕНЕВА, 19 февраль. (ТАСС). Кичә Берлинда «Көнчыгыш фронтта кризис һәм тоталь сугыш турында» Геббельс речь белән чыккан. Ул, хәзерге вакытта Германия армиясе Совет—Германия фронтында кризис кичерә, бу кризис үзенең иң югары ноктасына җитте һәм ул, «Сталинград янында немецларга ясалган трагедияле ударның» нәтиҗәсе булып тора, дип белдергән. «Без,—дигән ул,—көнчыгышта авыр хәрби хәл кичерәбез. Бу кышта дошманның басымы бик көчле булды, ул барлык кешелек һәм тарихи аңламаларны узып китә». Германиянең җиңелүләренең җитдилеген күрсәтеп, Геббельс, тагын бер тапкыр бөтен Европа өчен «большевистик куркыныч» турындагы әкиятне сөйләде.

Геббельс гитлерчы башлыклар «Советлар Союзының хәрби потенциалына бәя биреп җиткермәделәр» һәм хәзер «фактлар нинди авыр һәм нинди каты булсалар да аларга туп-туры карарга туры килә» дип икърар иткән.

Сугышның бөтен барышында, СССР ны бик тиз һәм җиңел генә җиңәбез дип немецларны алдап килгән Геббельс, Германия армиясенең хәзерге җиңелүләренең сәбәпләре турында бер сүз дә әйтми киткән. «Хәзер,—дигән ул,—бу нәрсәләр барысы да ничек килеп чыктылар соң, дип сорар вакыт түгел. Бу соңрак ясала торган отчет өчен калдырылачак, ул отчет без дучар булган бәхетсезлекнең тирән һәм фаталь әһәмиятен күрсәтәчәк».

Геббельс тоталь мобилизацияне үткәрү максаты белән барлык көчләрне куярга чакырган. Немецлар, дигән Геббельс, күптән инде авыр корбаннар бирәләр, ләкин хәзерге хәл «халыкның тормышын киләчәктә тагын да гадиләштерүне» таләп итә. «Дошман Германия чикләреннән әлегә ерак тора дип,—дигән Геббельс,—беркем дә моментның авырлыгын кечерәйтмәскә тиеш». Геббельс, Германиянең генә түгел, бәлки «Европаның Германия карамагындагы шактый өлешенең дә» хәрби потенциалын соңгы чиккә кадәр файдалану таләп итләчәкдигән. Шул ук вакытта Геббельс, Германия үзенең «союзникларына» исәп тота алмый дигән фикерне аңлаткан. «Әгәр дә,—дигән ул,—Германия сугышта җиңелсә, ул вакытта без үзебезнең дусларыбызны бармак белән генә саный алырбыз».

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность-транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ 650 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 282